وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№11 (108). 28 октябрь 2011 / 1-зөлхиҗҗә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



"Таян Аллага" конкурсына йомгак ясалды ▷2◁



Ильяс ХАЛИКОВ: "Мөнәҗәтләр яңа буынны тәрбияләүдә хезмәт итә ала" ▷3◁



Хатыным миңа еш үпкәли ▷4◁

## ХӘЕРЛЕ ХАҖ СӘФӘРЛӘРЕ БУЛСЫН!

**Соңгы елларда күпләр үзләренең тормышлары турында җитди уйлана башлады. Без үткәнебезне һәм бүгенге көнебезне өр-яңадан аңларга өйрәнәбез. Вакыт узган саен рухи асылыбыз, башлангыч халәтебез турында уйланабыз. Рухи азык эзләп, тирә-юнебезгә яңача карый башлыйбыз. Әле күптән түгел генә зурлап Ураза гаетен үткәргән идек, инде хаҗ кылу вакытына да кердек. Миллионлаган хаҗилар, рухи яктан чисталыкка ирешү нияте һәм үзләренең асылларына, башлангыч халәтләренә кайту теләге белән Мәккәгә юл тотты. Менә ни өчен елдан-ел Изге Кәгъбәтуллага баручылар саны арта бара: алар анда Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавына һәм рәхим-шәфкатенә ирешү өчен юнәлә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдисендә хаҗ кылып кайтучылар турында болай ди: "Хаҗ кылып кайткан кеше хаҗ вакытында буш, бозык сүзләр сөйләмәсә һәм бозыклыклар кылмаса, ул яңа туган сабый бала кебек, гөнаһларыннан арынып, пакьләнеп, чистарынып калыр". Хаҗ иманыбызны ныгыта, мөселманнарны изге гамәлләр кылырга өнди, ихласлылыкка чакыра. Кайвакыт, хаҗиларның изге гамәл кылуларын күреп, кешеләрнең шулкадәр кыска вакыт эчендә үзгәрә алуларына гаҗәпләнәсең, сокланасың.**

**Шунысын да онытырга ярамый: хаҗ сәфәре - чит илгә чыга торган гади-гадәти генә сәфәр түгел, иң беренче чиратта, ул - зур җаваплылык, рухи яктан ачылу һәм үз өстеңдә эшләү. Җиңел булмаячак: сынаулар, күңел аздыручы нәрсәләр дә булуы ихтимал. Юлдагы авырлыкларны һәм кыенлыкларны үтеп кенә, күңелегезнең чистарынуына ирешә алачаксыз. Аллаһка чын күңелдән бирелеп, аның рәхим-шәфкатенә өмет итәргә кирәк. Күпләр өчен иманнарының ныклыгын сынау һәм тормышларының асыл кыйммәтләрен аңлау өчен дә яхшы мәктәп булыр бу. Ислам диненең фарыз гамәлен үтәргә алынучыларга хәерле сәфәрләр теләп калабыз. Республикабызга исән-имин әйләнеп кайтып, яңа көч белән динебезне тарату насыйп булса иде.**

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

## ҺӘР МӘЧЕТ ЯНЫ КОРБАН ЧАЛУ УРЫНЫ ТҮГЕЛ

**Быел корбанлык сарык уртача 4 мең сум тора. Бу турыда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы утырышында карар да кабул ителде.**



Шулай итеп, корбан сарыгы бәясе, узган ел белән чагыштырганда, әллә ни күтәрелмәде. Бүтән мәгълүмат чаралары биргән хәбәрләргә караганда, бәя 3500 сумнан алып биш мең биш йөзгә кадәр тирбәлә. Әйтик, Казандагы "Мәрҗани" мәчетендә бер корбанлык "быел 4500-5000 сум булыр", диделәр.

### *Казанда корбан кайларда чалыначак?*

Татарстан башкаласында алтмышлап мәчет бар. Әмма аларның барысы да корбан чалу урыны була алмый. "Быел шәһәрдә корбан 3-4 урында гына чалыначак. Бу гамәлне үтәү шартлары булган мәчетләргә генә бу эшне башкарырга рөхсәт ителгән. Әйтик, "Мәрҗани", "Ризван" мәчетләренә, шулай ук шәһәребез бистәләрендәге кайбер иман йортларына", - диде "Мәрҗани" мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов.

Корбан чалу үтәчәк төп урын - шәһәр үзәгендәге "Мәрҗани" мәчетенә караган мәйдан. Дин әһелләре биредә санитар нормаларга туры килгән махсус урында казанлыларга изге ниятләрен тормышка ашырырга ярдәм итәргә әзер. Тагын бер махсус урын бар - анысы Бертуган Петряевлар урамында.

### *Әле соң түгел...*

Бүгенге көндә "Мәрҗани" мәчетенә йөзгә якын кеше корбан чалдырырга теләк белдереп мөрәҗәгать иткән инде. Шулай да, Илфар хәзрәт әйтүенчә, Казанда әлеге иман йортында һәм башка урыннарда да заказлар кабул итү дәвам итә. Тагын шунысын да әйтергә кирәк, 6 ноябрьдә корбан чалдырырга өлгермәгәннәр **7, 8 ноябрь** көннәрендә дә килә алачак.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды да корбан чалуга гаризалар кабул итә. Корбан ите мохтаҗ гаиләләргә, ятим-мескеннәргә таратылачак. Бер корбанлыкның бәясе - 4500 сум.

Алар теләге булганардан гаризаларны Казанның Лобачевский урамында урнашкан 6 нчы йортта кабул итә.

***(Ахыры 2 нче биттә.)***

# ЧЫН ХАҖИНЫҢ ХАҖЫ

***Тугры хәлифәләрнең бишенчесе Гомәр ибне Габделгазиз хаҗ сәфәренә кузгала. Аның ике дөясе һәм хаҗга барып кайтырлык мал-туары була. Ләкин Гомәр Кәгъбәтуллага хәтле барып җитә алмый. Ул су буена утырып хәл алырга ниятли. Ашап-эчеп, ял итеп ятканда ул бер хатын-кызны күреп ала. Әлеге хатын яр буеннан ашыгып барып, елгадан нәрсәдер алмакчы була икән. Гомәр ибне Габделгазиз бераз күтәрелеп караса, ни күрсен, суда тавык үләксәсе ята. Ул хатынга болай ди:***



- Әй, мөэминә! Сез белмисезмени мөселман кешесенә үләксә ите ашау хәрам икәнлеген!

Әлеге хатын башын бераз күтәреп:

- И, мосафир, мин сезне белмим, танымыйм, - ди. - Мин галимә дә түгел, җитәрлек гыйлемем дә юк. Әмма хәзрәтләр авызыннан: "Өйдә бер (хәләл) ризык та булмаганда, үтереп ашыйсы килгән чакта, җанны саклап калу өчен мәет итен дә ашау ярый", - дигән сүзләрне ишеткәнем бар иде. Өченче көн китте инде, минем өемә бернинди дә ризык кергәне юк. Ирем (хәләл җефетем) вафат булды. Бер күкрәк сөте имгән, моннан тыш, тагын өч һәм алты яшьләрдәге балаларым бар. Ирем һәр көнгә җитәрлек ризык алып кайта иде. Мин әлеге үләксә тавыкны "бәлки бу безнең бүген ризыгыбыз булыр", дип алмакчы идем. Аны ашарга ярамаганлыкны яхшы аңлыйм, әмма нишлим соң инде, бүтән чара юк бит?! - ди.

Бу сүзләрне әйткәч, хатын-кызның күзләреннән яшьләр ага башлый. Хаҗга юнәлгән Гомәр бер дөясен, юл чыгымнарын капларга җитәрлек булган бөтен мал-туарын шушы апага тапшыра.

- Әй, мөэминә! Син минем кебек бер зәгыйфь бәндәгә дога кыл, - дип әйтә Гомәр.

Бу хатын-кызның шатлыгы дөньяга сыймый. Ул бик тә куанып, күз яшьләре белән Ходайга ялварып дога кыла:

- Синең кем икәнлегеңне дә белмим, ләкин Аллаһ бәндәсе бул, әүлиялардан бул. Син бик нык ярдәм иттең безгә, - ди.

Һәм Гомәр монда килгән дөясе белән бернинди ризыксыз кире кайтып китә, хаҗга бармый. Ул өенә кайтып, йорт эшләрен дәвам иттерә. Хаҗга киткәннәр әкренләп кайта башлыйлар. Кайтучыларның һәммәсе Гомәргә болай дип әйтә икән:

- Йә, Гомәр, Аллаһы Тәгалә синең хаҗыңны кабул кылсын!

- Мин бит хаҗга бармадым, - дип җавап бирә Гомәр.

- Әй, безне алдалама инде. Булдың бит...

Башта бер-ике кеше, аннан соң күпләгән халык: "Йә, Гомәр, хаҗың кабул булсын!" - дип дәшә башлагач, Гомәр үзе дә гаҗәпкә кала.

- Ни сөйлисез соң сез? Бәлки, сез мине кем белән булса да бутыйсыздыр. Мин бармадым бит, ярты юлдан әйләнеп кайттым, - дип җавап кайтара торган була ул.

- Юкны сөйләмә. Безнең белән корбан чалдың, безнең белән Бәйтулла тарафына тәваф кылдың.

Бу сүзләрдән соң Гомәр хәйран кала. Ястү намазын укыганнан соң да йокыга китә алмыйча ята. Кинәт кенә тирән йокыга чума да, төш күрә. Һәм шул төшендә бер тавыш ишетә. Шул аваз әлеге бәндәнең акылына, җанына, рухына эндәшә икән:

- Йә, Гомәр! Синең хаҗ кылмыйча, юлыңа очраган фәкыйрь, мескен, мохтаҗ хатын-кызны һәм аның сабый балаларын шатландырганың, бар байлыгыңны аларга тапшырып, ярты юлдан әйләнеп кайтканың өчен Аллаһы Тәгалә быел барлык хаҗиларның да хаҗларын кабул итте. Ул синең сурәтеңдәге бер фәрештәне иңдерде. Фәрештә исә сезнең өчен корбан чалды, Кәгъбатулла, Сафа-Мәрва тирәсен дә әйләнде. Һәм агымдагы елда хаҗ кылучыларның хаҗлары синең шушы гамәл-адымың хөрмәтенә кабул ителде.

***(Ахыры 3 нче биттә.)***

## Мөхтәсибәт ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### *КУКМАРА*

**Кукмара районы имам-мөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллин хаҗ сәфәренә юл тотты.**

**Кукмара мәдрәсәсе яңа уку елын быел да биш йөзләп шәкерт белән каршы алган. Укулар 1 октябрьдән башланган. Уку йорты ишекләре теләге булган һәр кеше өчен дә ачык. "Мәдрәсәбезгә йөрергә теләүчеләргә яшь буенча бернинди дә чик куелмаган. Хәзерге вакытта укуларга уникедән алып туксан яшькә кадәргеләр килә", - диде З.Сәмигуллин. Әлеге мәдрәсәнең тагын бер үзенчәлеге бар: шәкертләр мәдрәсәдә яшәп-торып укымый. Авыл кешеләре дәресләргә якшәмбе көнне килеп йөри, алар өчьеллык программа нигезендә белем ала. Ә Кукмара халкы бирегә атнаның дүрт көнендә - чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә көннәрендә җыйнала. Монда һәрбер дин гыйлемен үзләштерүчегә шәхси якын килергә тырышалар: вакыты булган пенсионерлар көндез килеп укыса, эшләүчеләр мәдрәсә ишекләрен эштән соң ача. Киләчәкне күздә тотып, дөньяви фәннәрне дә кертеп, дүртьеллык программа төзегәннәр. Бүгенге көндә мәдрәсәдә өч ел укыганнан соң, имтихан тапшырып, дипломлы була аласың. 2009 елны Кукмара Җәмигъ мәчете янында мәдрәсә өчен яңа бина төзелеп ачылган иде (ә мәдрәсә үзе рәсми рәвештә 1998 елдан бирле эшли) - дәресләр нигездә шунда уза, ә мәдрәсәгә сыймаган халыкны мәчеткә алып керәләр. Мәдрәсә үзенә берьюлы йөз иллеләп кешене кабул итә ала. Анда барлыгы унике бүлмә бар, шуның тугызы - уку сыйныфлары.**

**Шулай ук Олыяз, Уразай, Туембаш авылларында да дини дәресләр башланган. "Укуларны ныклап авылларда юл төшкәннән соң, кар яугач башларга ниятлибез. Гадәттәгечә, аяк асты рәтләнгәнне көтәбез, - диде Зиннур хәзрәт. - Теләге булган һәркемгә башлангыч дини белем бирүне максат итеп куябыз. Шушы юнәлештә эш алып барырга тырышабыз. Башка елларны безнең районның кырыклап авылында укулар оештырыла иде. Әлхәмдүлилләһ, башлангыч дини белем алу өчен авылларда да барлык мөмкинлекләр бар".**

***P.S.: Кукмарада дин әһелләре дә еш кунак була. Мисал өчен, 6 октябрь көнне Казан шәһәре казые Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин килгән. Ул биредә мөселманнар җыенында катнашкан. Мондый җыен Кукмарада һәр ай саен уза икән. Катнашучыларның күпчелеге - мәдрәсә шәкертләре. Җәмигъ мәчеттә узган октябрь җыенында ике йөз иллеләп кеше катнашкан.***

### *ТУКАЙ*

15 октябрь көнне Тукай районы мөхтәсибәтендә районның мәчет каршында дини белем бирүче мөгаллимнәр җыелышы булып узган. Әлеге җыелышта 22 мөгаллимә катнашкан.

Тукай районы имам-мөхтәсибе Җәүдәт хәзрәт Харрасов сүзләренә караганда, 24 октябрь көнне районда авыл хуҗалыгы предприятиеләреннән гошер сәдакасы җыю мәсьәләсе күтәрелгән. Администрациядә узган җыелышта предприятиеләр гошерне мөхтәсибәткә тапшырырга тиеш, дигән нәтиҗәгә киленгән. "Тукай мөхтәсибәтендә халыктан да гошер сәдакасы җыю эше дәвам итә. Гошерне Чаллы шәһәрендәге "Ак мәчет" мәдрәсәсенә тапшырабыз", - дип белдерде Җәүдәт хәзрәт. Тукай районындагы 43 мәхәлләнең унсигезе әлеге эштә актив катнашкан.

**Яңалыкларны Нияз САБИРҖАНОВ җыйды**



# "ТАЯН АЛЛАГА" конкурсына йомгак ясалды

**Билгеле булганча, узган елның 2 ноябрендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышлап, "Таян Аллага" дип аталган II конкурс игълан иткән иде. 20 октябрь көнне "Ностальгия" ресторанында әлеге конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы уздырылды.**

Кичәне алып барган Ришат Хәмидуллин иң әүвәл Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәизгә сүз бирде. Ул исә чакырылган кунакларга - танылган шагыйрь Разил Вәлиев, язучылар Мөсәгыйть Хәбибуллин, Рәфкать Кәрами, әдәби тәнкыйтьче-галим Фоат Галимуллин, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, быел Тукай бүләген алган Ркаил Зәйдулла һ.б. олуг рәхмәтләрен белдерде. Диния нәзарәте рәисе шулай ук бу конкурсны оештыруда зур көч куйган Вәлиулла хәзрәт Якуповка зур рәхмәтен җиткерде. "Татар милли әдәбияты үзенең Тукайларын, Әмирханнарын, Кол Гали кебек талантлы әдипләрен көтә. Киләчәк буыннарга барып җитәрлек әсәрләрен барлый", - диде Илдус Фәиз. "Таян Аллага" конкурсы шушы мәсләкне күз уңында тотып оештырылган да инде.

Язучылар исә кешене әдәп-әхлаклы итеп тәрбияләүдә әдәбиятның тоткан роле зур булуы хакында сөйләде, - дип яза tatar-islam.ru сайты.

Менә яшьләр өчен дулкынландыргыч мизгелләр дә килеп җитте. Жюри (аның составына филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университетындагы Филология һәм сәнгать институтының XX-XXI гасыр татар әдәбияты һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры Фоат Галимуллин, филология фәннәре кандидаты, шул ук кафедраның доценты Фәридә Хәсәнова, филология фәннәре кандидаты, шул ук кафедраның өлкән укытучысы Рамил Ханнанов, тарих фәннәре кандидаты Вәлиулла Якупов кергән) "Гран-при"ны яшь шагыйрь, "Шәһри Казан" газетасы хезмәткәре Фәнил Гыйләҗевка бирергә, дигән карарга килгән. "Шигърият" номинациясендә беренче урын - Булат Ибраһимга, икенче бүләк - Руфинә Габдрахмановага, өченче урын Ядкәр Шәраповка насыйп булды. "Чәчмә әсәрләр" буенча Гөлнирә Хөсәенова, Алмаз Мансуров, Айдар Шәйхин җиңү яулады. 30 яшькә кадәрге 22 егет һәм кыз кызыксындыру бүләгенә лаек дип табылды.

Әлеге бай эчтәлекле кичәдә чыгыш ясаучылар күп булды. Жюри рәисе Ф.Галимуллин сүзләренә караганда, конкурска дип килгән 163 әсәргә бәя бирелгән. Аларның йөз егерме тугызын шигырьләр, утыз икесен чәчмә әсәрләр тәшкил итә. Гөлнирә Хөсәенова исемле яшь прозаик конкурска үзенең повестен тәкъдим иткән.

Кичә ахырында ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз: ""Таян Аллага" конкурсы дәвамлы булыр, дип ышанып калабыз. Аның бәһасен, кыйммәтен киләчәк күрсәтер", - дип белдерде.

Минем уйлавымча, яшьләребезне дингә, иманга тарту, иҗади рух белән яшәтү өчен менә дигән чара иде бу. Ә инде яшь каләм әһелләре иҗатыннан торган 288 битле китапның "Иман" нәшриятында басылып чыгып, укучыларга таратылуы нур өстенә нур булды.

**Хаҗип ӘХМӘТША**
**Автор фотосы**

# ҺӘР МӘЧЕТ ЯНЫ КОРБАН ЧАЛУ УРЫНЫ ТҮГЕЛ

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Кызыксынучылар түбәндәге телефоннар аша элемтәгә керә ала: +7 (843) 236-46-32, 264-60-08. Факс: +7 (843) 236-37-62. Сарык өчен аста китерелгән исәп-хисап счёты аша акча күчерергә мөмкин:

**ИНН 1655068682**
**ОГРН 1091600003153**
**р/с 40703810400020000071 в ОАО "Ак Барс" Банк в г.Казани**
**к/с 30101810000000000805**
**БИК 049205805**

Казанның Юдино бистәсендәге дин әһелләре Корбан бәйрәме якынлашу турында хәбәр таратуның иң гади юлын сайлаган. Берничә атна элек бистә йортларының подъезд ишекләренә "Корбан бәйрәме якынлашу уңаеннан "Җомга" мәчете янында корбан чалу йоласын үтәү оештырыла", - дип язылган белдерүләр элеп чыктылар. Шул рәвешле бөтен бистә мөселманнары Корбан бәйрәме җитүеннән хәбәрдар булды.

Һәм күп урыннарда белдерү кәгазенең телефон язылган өлеше тиз арада юкка чыкты. Димәк, корбан чалдырырга теләүчеләр аз түгел. Тик шул хакта белешү максатыннан берничә мәртәбә белдерүдә язылган телефонга шалтыратуга карамастан, трубканы алучы булмады... Бәлки инде корбанлык сарыклары беткәндер... - дип яза Татарстан Республикасының intertat.ru электрон газетасы.

## *Галәм изге нур белән тула*

Гает намазы Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә укыла. Ул быел 6 ноябрьгә туры киләчәк.

Бу бәйрәм көнне мөселманнар иртә таңнан торып мәчетләргә гает намазы укырга бара. Гаеткә барганда юлда туктап: "Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләһә илләллааһу уәллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр үә лилләәһил хәмде", ягъни "Аллаһ бөек, Аллаһ бөек, бөек Аллаһтан гайре Иләһ юктыр, Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактау булсын", дип тәгъбир әйтү сөннәт гамәлләрдән санала. Гает намазыннан соң мөселман кешесе корбан чалып, туганнарын, күршеләрен, фәкыйрьләрне сыйларга тиеш.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы тәкъдим иткән үрнәк вәгазьдә әйтелгәнчә, "бу изге көндә күк капуслары ачык була, барлык фәрештәләр Аллаһтан адәм балаларының гөнаһларын кичерүне сорап, изге тәсбихтә булалар. Бу изге таңда мәчет манараларыннан әйтелгән азан, кылынган изге гамәлләр хөрмәтенә Аллаһ рәхмәте белән галәм изге нур белән тула".

Корбан бәйрәме тарихына килгәндә, Ибраһим галәйһиссәләмнең озак еллар баласы булмый. Ул: "Әгәр улым туса, мин аны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен корбан итәр идем", - дип, нәзер әйткән була. Ибраһим галәйһиссәләмнең улы туа, аңа Исмәгыйль исеме бирелә. Берничә еллар үткәч, Ибраһим (г.с.) Мәккә шәһәрендә булган вакытта, төшләр күрә башлый. Ул төшләрдә Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәләмгә улы Исмәгыйльне корбан чалырга куша.




Дини китапларда: "Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә бәндәнең каннарын түгүче түгел, ул бары Ибраһим галәйһиссәләмне шул рәвешчә сынады, Исмәгыйль галәйһиссәләм үзе дә сынатмады. Әтисе аны корбан итеп чалырга алып барганда, шайтан котыртты: "Сине атаң мәйданга алып бармый, ул сине чалырга алып бара бит", - дигән иде. Исмәгыйль галәйһиссәләмнең иманы бик нык була. Ул бу хәлдә: "Әгәр дә бу Аллаһның әмере булса, без аны үтәячәкбез", - дип әйтеп, шайтанны ташлар атып куа. Ибраһим галәйһиссәләмнең улы Исмәгыйль (г.с.) арасында булган сөйләшүне Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә дә китерә: "Ибраһим әйтте: "Ий углым, мин төшемдә Аллаһ тарафыннан сине корбан итеп чалырга боерыламын, уйлап карачы, бу эшкә ничек карыйсың?" Улы Исмәгыйль әйтте: "Ий атам, ни белән боерылган булсаң, шуны эшлә, мин Аллаһ хөкеменә ризамын, бу эштә мине, Аллаһ теләсә, сабыр итүчеләрдән табарсың" ("Саффат (Сафта торучылар)" сүрәсе, 102 нче аять). Ибраһим улын бугазлыйм дип торган мәлдә Җәбраил фәрештә килеп, аны тыйган. Аллаһы Тәгалә әмере белән, улы урынына бер куй китереп, шуны корбан итеп чалырга кушкан. Җәбраил фәрештә шушы куйны китергәч: "Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр", - дип әйткән. Ибраһим (г.с.) тәкбирне ишеткәч: "Ләә иләһә илләллааһу уәллаһу әкбәр", - дигән һәм аннан соң Исмәгыйль (г.с.) болай дип өстәгән: "Аллаһу әкбәр үә лилләәһил хәмде". Хәзерге вакытта мөселманнар бу сүзләрне Корбан бәйрәме көннәрендә һәр фарыз намаздан соң кабатлый", - диелгән.

**Айзирәк ГӘРӘЕВА**

# АТЛАСОВ ҺАДИ (ӘХМӘТҺАДИ) МИФТАХЕТДИН УЛЫ (ҺАДИ АТЛАСИ)

***1903 елның маеннан Бөгелмә өязе Әлмәт авылы (хәзерге Әлмәт шәһәре) имам-хатыйбы, мәдрәсә мөдәррисе итеп билгеләнә. Мәдрәсә каршында кызлар мәктәбе ача. Киң кырлы эшчәнлек алып бара.***




1907 елда Һади Атласи Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана. Анда "Мөселман хезмәт таифәсе" әгъзасы, "Дума" газетасын чыгаручыларның берсе була. Бөтенроссия мөселманнарының III корылтае депутаты. Патша хөкүмәтенең милли белем бирүдәге сәясәтен тәнкыйтьләп, 1906 елда "Яңа низам вә голәмаларымыз" исемле публицистик хезмәтен бастыра, шуның өчен 1909 елда өч айга төрмәгә утыртыла. Иреккә чыгарылгач, имам һәм мөдәррис вазифаларыннан баш тартырга мәҗбүр була. Полиция күзәтүе астында гаиләсе белән Бөгелмә шәһәрендә яши башлый.

Әлеге хәлләргә дә карамастан, ул фән һәм әдәбият өлкәсендә эшчәнлек алып бара. Зур тырышлык куеп тарихи материаллар җыю, тарихи әдәбиятыбызны өйрәнү өстендә эшли. Шул хезмәтләренең җимешләре буларак, 1911-1914 елларда бер-бер артлы аның "Себер тарихы", "Казан ханлыгы", "Сөембикә" исемле тарихи әсәрләре басылып чыга. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы була (1913). Бер үк вакытта "Йолдыз", "Вакыт", "Шура", "Мәктәп", "Аң" һ.б. вакытлы басмалар белән хезмәттәшлек итә.

Февраль революциясеннән соң милли демократик хәрәкәтнең актив әйдәүчесенә әверелә. Россиядә яшәүче төрки халыкларның милли-мәдәни мохтариятләрен оештыруны яклап чыга. Бөтенроссия мөселманнарының I һәм II корылтайларында катнаша, II корылтайда Эчке Россия һәм Себер мөселманнарынын милли-мәдәни автономиясен төзү нигезләрен әзерләүче комиссиягә әгъза итеп сайлана. 1917-1918 елларда Милләт Мәҗлес депутаты, төркичеләр фракциясе әгъзасы була.

КОМУЧ хакимлеге вакытында Бөгелмә шәһәренең җирле үзидарәсендә актив эшчәнлек алып бара (1918). Бөгелмәне Кызыл Армия алгач, Азәрбайҗан Демократик Республикасынын башкаласы Ганҗә шәһәренә күчеп китә. 1920 елның сентябрендә Совет хөкүмәте тарафыннан кулга алына һәм Баку шәһәрендәге Баилов төрмәсенә ябыла. ТАССР житәкчелеге таләбе белән туган җиренә кайтарыла. Чистай шәһәрендә аклар контрразведкасына ярдәм итүдә гаепләп уздырылган мәхкәмә утырышында аклана һәм 1921 елның апрелендә иреккә чыгарыла. 1920 елларда Бөгелмә кантонының Шөгер, Зәй, Каратай авыллары һәм Бөгелмә шәһәре мәктәпләрендә укыта. Татар язуын гарәп графикасыннан латиницага күчерүгә каршы чыга. 1929 елда кабат кулга алына һәм Соловки лагерена озатыла. 1933 елда сәламәтлеге начараю сәбәпле, лагерьдан азат ителә. 1934 елда елда Архангельскидан Бөгелмәгә кайтып ярты ел торгач, Һади Атласи гаиләсе белән Казанга күчеп килә. 1936 елда ул тагын кулга алына. Совет хөкүмәтенә каршы эш алып барган милләтчел контрреволюцион оешма төзүдә нахакка гаепләнеп, 1937 елның октябрендә атып үтерелә. Шулай итеп, татар халкының мәшһүр улларыннан булган Һади Атласи кебек биниһая зур шәхеснең гомере ул чордагы күп зыялыларныкы төсле тәмамлана. 1958 елда ул аклана һәм реабилитацияләнә.

**Мәкаләне Рәшид МАЛИКОВ әзерләде**

## Ильяс ХАЛИКОВ:

# "МӨНӘҖӘТЛӘР ЯҢА БУЫННЫ ТӘРБИЯЛӘҮДӘ ХЕЗМӘТ ИТӘ АЛА"

**Мөнәҗәтләр - татар халкы өчен традицион булган, хәзерге вакытта халык арасында танылып килүче борынгы җыр жанры. Ел саен без яңа башкаручыларның барлыкка килүен беләбез. Газета укучыларыбызны яшь башкаручы, тиздән авторлык альбомын чыгарырга ниятләүче Ильяс Халиков белән таныштырырга телибез.**



**Тулы исеме: Ильяс Йосыф улы Халиков.**
**Туган елы: 1983 елның 26 апреле.**
**Туган ягы: Татарстанның Мамадыш районы Уразбахты авылы.**
**Ярата: гаиләсен, дусларын, хәләл булган барлык ризыкны.**
**Яраткан цитатасы: "Кечкенә эштә ялгышты икән, димәк, олы эштә дә ялгышачак".**

"Иң яраткан фәннәрем - алгебра һәм музыка дәресләре иде. Кайбер көннәрне әзерләнмичә килеп, "ике"ле дә алгалый идем", - дип сөйли ул мәктәп еллары турында. Милли татар көрәше белән шөгыльләнә, ике тапкыр көрәш буенча чемпион кала, Муса Җәлил исемендәге призга ия була.

***- Ильяс, музыка Сезнең тормышыгызның күпме вакытын ала?***

- Мин үзем Россия ислам университетында педагогика һәм психология дәресләрен укытам. Ә җырлау - ул минем әлегә хобби гына. Көйләрне үзем язам. Ә җыр сүзләрен тормыш иптәшем Нурфия иҗат итә.

***- Беренче башкарган җырыгызны исегезгә төшерә аласызмы?***

- Әлбәттә. XX гасырның 90 нчы еллары иде ул. Мин бәләкәй чакта җырлый башладым. Беренче тапкыр сәхнәдән "Әссәламегаләйкем" җырын башкардым. III сыйныфта укыганда миңа гармун бүләк иттеләр, аннары параллель рәвештә баянда уйный башладым. Минем әти-әнием авыл тормышы белән яшәүчеләр, хезмәт сөюче кешеләр. Кичләрен мин аларны баянда уйнап, кечкенә генә концерт куеп ял иттерә идем. Гомумән, музыка белән мавыгуым шулайрак башланды.

***- Мөнәҗәтләр белән кайчаннанрак кызыксына башладыгыз?***

- Намаз укый башлагач. Ягъни 1997 елдан. Минем әби-бабам һәм олы абыем мәдрәсәдә укыды. Мин дә алар юлыннан киттем. Холык-фигълемә олы буынның тәэсире зур булды. Минем мөнәҗәт җырлаганымны безнең әбиләребез тыңларга ярата иде. 2000 елда мин КДПУга (хәзерге КФУ) укырга кердем. 1998 елда Россия ислам университеты ачылган иде. Дини тематика минем күңелемә хуш килә башлады.

***- Мөнәҗәт белән нәшидләр арасында сайланып, сез татар гореф-гадәтләренә туктадыгызмы?***

- Нәшидләр кергән гарәп җыентыкларын тыңлаганда, миңа: "Нигә соң безгә (аеруча бүгенге бозык попса фонында) мөнәҗәтләр башкаруыбызның борынгы тәртибен яңадан башлап җибәрмәскә?" - дигән уйлар килде. Шуңа да мин татар музыка гадәтләрен мөнәҗәт буларак янә башлап җибәрергә һәм аларны популярлаштырырга булдым. Ә бит үз тормышыбыз, үз рухи байлыгыбыз, үз динебез кебек мәңгелек һәм мөһим темалар турында җырларга кирәк! Укытучы буларак, мин мөнәҗәтләрнең яңа буынны тәрбияләүдә хезмәт итә алачагына, аны чисталыкны, намуслылыкны һәм тәкъвалыкны пропагандалауда булышлык итүен яхшы аңлыйм.

***- Сезнең репертуарыгызда җырлар күпме?***

- Мин - автор-башкаручы. Хәзерге вакытта 12 җырым бар. Хатыным - сүзләрен, ә мин көен язам. Төп темалар: әти-әни, туган як, Кыямәт көне, Аллаһы Тәгаләне мактау, Коръән уку.

***- Сез үз альбомыгызны чыгарырга әзерләнәсезме?***

- Әйе, әмма моның өчен беркадәр финанс мөмкинлеге кирәк. Әлегә альбом яздыру өчен спонсорлар эзләү белән мәшгульмен. Мәсәлән, бер генә җыр яздыру өчен дә биш меӊ сум акча кирәк. Иң мөһиме - минем шәхси танылуым түгел, ә бәлки, башкарган мөнәҗәтләрем аша кешеләрнең хак дин юлын эзләп табулары.

***- Сезгә илһам кайдан килә?***

- Аллаһы Тәгаләдән дип уйлыйм. Һәркемгә сәләт бирелгән, аны дөрес итеп кулланырга гына кирәк. Әгәр дә шулай эшлисең икән, алда сине уңыш көтә. Беренче балам тугач, беренче мөнәҗәт барлыкка килде. Бу биш ел элек иде. Гаиләм - минем өчен шулай ук илһам чыганагы. Яхшылыклар кылып калырга һәр кеше омтылырга тиеш. Мисал өчен, әгәр дә кеше азан әйтә ала икән, ул моңарга бөтен көчен куярга тиеш. Чөнки, миңа калса, азан никадәр матуррак яңгыраса, мәчеткә кеше шулкадәр күбрәк йөриячәк. Ямьсез азан кешене биздерә ала. Әгәр дә инде ул ихлас күңелдән әйтелә икән, шул вакытта аның тәэсире көчлерәк була.

***- Мөселманнар арасында мөнәҗәтләргә карата төрле мөнәсәбәт яшәп килә. Сезнең тәнкыйтькә дучар булганыгыз юкмы?***

- Әйе, кайберләүләр моны "бидгать, бу - ислам диненә туры килми", дип әйтә. Мин моның белән килешмим. Беләсезме, йөз ел элек дөньяга килгән татар театрын шулай ук кабул итмәгәннәр, ә хәзер дин әһелләребез үзләре үк театрга йөри. Аннан соң мөнәҗәтләргә хас борынгы гореф-гадәтләр дә бар бит. Бу - мөселманнар алып барырга тиеш булган дәгъвәтнең бер өлеше. Минем сәхнәдә үз-үземне тотышым, киенү рәвешем милләтебезне баета. Үземнең җырларым белән яшьләргә дөрес юнәлеш бирергә телим. Мин халкыбызга хас булган киемнәрне күрсәтү яклы.

***- Кемнәрнең фикеренә колак саласың?***

- Әлбәттә, читтән хаталар яхшырак күренә, шуңа да кеше үз фикерен сиңа белдерә. Әмма күп очракта аларның барысына да игътибар итә башласаң, син үз күңелеңне ирексезләп читкә тайпыла башлыйсың. Шуңа күрә дә борынгыларның мондый акыллы сүзе бар: "Кешене тыңла, үзеңнекен эшлә". Икеләнү вакытларында Аллаһтан ярдәм сорап, күңелемне тынычландырам.

***- Бүгенге көндә чын мөселманча мөнәҗәт нинди булырга тиеш?***

- Мөнәҗәт тыңлаганда кеше хакыйкатьне һәм иманны аңларга, тәкъвалыкны сизәргә тиеш. Мөнәҗәт башкарган чакта ислам кагыйдәләренең барысы да үтәлү мөһим. Шул ук вакытта ул яшьләрне җәлеп итү өчен үз стилендә калырга тиеш. Әмма попса дәрәҗәсенә үк төшәргә тиеш түгел инде.

***- Сезгә сәхнәдә еш чыгыш ясарга туры киләме?***

- Мин әле яшь, ләкин миндә билгеле бер күләмдә чыгыш ясау тәҗрибәсе бар, дип әйтә алам.

***- Мөнәҗәтләрне ничек итеп популярлаштырырга мөмкин булыр, дип саныйсыз?***

- Барысы да гади: аларны радио-телевидениедә ешрак "әйләндерергә" кирәк. Һәм инде, әлбәттә, мөнәҗәтләр белән бәйле кызыклы конкурслар, фестивальләр үткәрергә кирәк, дип уйлыйм.

**Нияз САБИРҖАНОВ әзерләде**

# ЧЫН ХАҖИНЫҢ ХАҖЫ

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Гомәр уянып киткәннән соң төштә ниләр күргәнлеген аңлый, анализлый һәм бу хәлне башкаларга да сөйли.

Мөхтәрәм кардәшләрем! Әлбәттә, хаҗ кылу - фарыз гамәл, ул бик тә саваплы эш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдисендә хаҗ кылып кайтучы турында болай ди: "Хаҗ кылып кайткан кеше хаҗ вакытында буш, бозык сүзләр сөйләмәсә һәм бозыклыклар кылмаса, әйтерсең лә ул яңадан дөньяга килгән сабый кебек гөнаһларыннан арынып, пакьләнеп, чистарынып калыр".

Ислам динендәге барлык гамәлләр дә саваплы. Хаҗ гамәлен үтәү адәм баласын нинди олы дәрәҗәләргә ирештерсә, шулай ук намаз уку, ураза тоту, бүтән кардәшләреңә авызыңдагы телең, кулың яисә малың белән ярдәм итү - боларның һәммәсе дә кешегә шундый ук дәрәҗәләр бирер. Әмма шушы изгелекләр бакчасында йөргән вакытта акыллы һәм зирәк мөселман кешесе, урынына һәм вакытына карап, Гомәр ибне Габделгазиз кебек изгелекнең иң кирәклесен сайлый белергә тиеш. Гомәрнең дә хаҗга юнәлүе изге эш иде. Әмма юлында очраган тол, мохтаҗ хатынга ярдәм кулы сузып, ул хаҗын кылмыйча, аның бөтен малын шушы мохтаҗ кешегә тапшырып, өенә кайтып китүе - тагын да зуррак, изгерәк гамәл булып чыкты. Ягъни, бер генә сүз белән әйткәндә, Гомәр - ихлас күңелле мөселман булганга күрә, ике изге эш арасыннан үтә дә әһәмиятлесен, моннан да файдалырагын, изгерәген сайлап ала белгән, дип нәтиҗә ясый алабыз.

Ни гаҗәп, хәзерге вакытта мөселманнар арасында бик сәер күренешкә тап булырга мөмкин. Алар: "Хаҗга бару - иң саваплы эш", - дип, әллә ничәшәр тапкыр хаҗга барып кайтулары белән мактанырга тотына. Һәм үзләрен бик тә саваплы, дәрәҗәле мөэминнәр дип хис итәләр. Бу - ялгыш фикер. Беренчедән, кайбер вакытта, хаҗ кылучыларны читтән күзәтеп торганда, аларның хаҗга барып кайтулары белән горурлану-масаю хисләрен уртаклашуларына да юлыгасың. Бу - бер дә дөрес түгел. Икенчедән, хаҗ гамәле сәламәтлеге, малы, мөмкинлеге булган кешеләргә генә фарыз. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә: "Әй, мөэминнәр, бурычка кереп булса да хаҗга барыгыз", - дип әйтмәде. Тагын бер мәртәбә шунысына да басым ясап узасым килә: хаҗ гыйбадәтен үтәү - сәламәтлеге, малы, юлы имин булган кешегә гомерендә бер генә тапкыр фарыз. Пәйгамбәребез (с.г.в.): " Хаҗ кылу - мөмкинлеге булган кешегә генә тиешле", - дип әйткән. Өченчедән, хаҗ гыйбадәте ислам дине кушкан барлык изгелекләр арасында иң беренче урында торып, иң изге гамәл булып саналса, Аллаһы Тәгаләнең иң сөекле бәндәсе Мөхәммәд (с.г.в.) гомерендә бер тапкыр гына хаҗ кылу белән чикләнмәгән булыр иде.

Кардәшләрем! Акыллы вә зирәк булырга Аллаһ Раббыбыз һәммәбезгә дә насыйп итсә иде. Күңелеңдә булган диндарлыгыңа таянып, Гомәр ибне Габделгазиз кебек изге гамәлләр арасыннан саваплырагын таба белергә язсын! Бер мәртәбә хаҗга барган булсагыз, икенче тапкырында үз урыныңа бүтән кешене җибәрегез яки хаҗ кылырга җитәрлек малыңны Гомәр кебек файдалы җирләргә сарыф итегез. Аллаһы Тәгалә үз ярдәменнән ташламаса иде!

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН,**
**Казан шәһәре казые,**
**"Шамил" мәчете имам-хатыйбы**

# Республикабызда "Сабыйга-2" акциясе уза

***18 ноябрьгә кадәр "Яңа гасыр" радиосы Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә "Сабыйга-2" акциясен уздыра.***

Әлеге чара кысаларында Казанның Киров районында урнашкан Балалар инфекцион хастаханәсенә ярдәм күрсәтеләчәк. Биредә әниләре ташлап киткән яңа туган сабыйларга "ватные палочки", памперслар, яңа туган сабыйларга яраклы киемнәр кирәк.



Балаларга ярдәм итәргә теләүчеләр түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итә ала: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт (ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия бүлеге). Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 236-52-12, 89872639889 (Гөлнара Садыйкова).

Ятимнәргә карата мөнәсәбәткә бәйле рәвештә Аллаһ илчесе (сгв): "Кем дә кем ятим баланы үзенә тәрбиягә ала, аның хокукларын саклый һәм башыннан ягымлы итеп сыйпый икән, шул кешегә Аллаһы Тәгалә, бу ятимнең башында күпме чәче бар, шул хәтле савап бирәчәк, бу ятимнең башында күпме чәче бар, шул хәтле гөнаһларын кичерәчәк һәм бу ятимнең башында күпме чәче бар, шул хәтле дәрәҗәләр бүләк итәчәк", - диелгән ("Мәҗмугатуль-бәян").

**DUMRT.RU**

# ОЧРАШУ УРЫНЫ – ӘЛМӘТ

***21 октябрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтеннән - беркетмәләр бүлеге мөдире Илшат Насыйбуллин, Татарстанның җәзаларны үтәтү буенча Федераль хезмәте (УФСИН) белән элемтәдә тору бүлеге җитәкчесе Айрат хәзрәт Зарипов, ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова, "Дин вә мәгыйшәт" газетасы мөхәррире Нияз Сабирҗанов, уку-укыту бүлеге белгече Айдар Кәрибуллин Әлмәт шәһәренә сәфәр кылды.***



Делегация Әлмәт мөхтәсибәте белән күреште, шәһәрнең Җәмигъ мәчетендә булды, район мәчетләрендә җомга намазы укыды, Әлмәтнең егетләр һәм кызлар мәдрәсәсе студентлары белән аралашты, мәчеткә йөрүчеләрнең сорауларына җавап бирде. Мөфтият вәкилләре шулай ук Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары Ирек Фәррахов белән очрашты, райондагы дини торыш турында сөйләшү алып барды.

# Балык бистәсендә эшләр гөрләп бара

**- Россия ислам университетына - 285, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәгә 78 капчык бәрәңге җыеп тапшырдык, - дип башлады үз сүзен Балык бистәсе районы имам-мөхтәсибе Сәүдәхан хәзрәт Гайнетдинов. - Шулай ук "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә дә 120 капчык бәрәңге әзерләп куйдык.**

Районда гошер сәдакасын җыю әле дә дәвам итә. Барлыгы биш йөз кырык капчыклап (22 тонна тирәсе) бәрәңге, 400 килограмм яшелчә җыелган. Киләсе атнага гошер сәдакасы җыюда актив катнашкан имамнарны бүләкләргә ниятлиләр. Әлеге эштә районндагы 46 мәхәлләнең утыз сигезе берөзлексез катнашкан.

Быел Балык бистәсе Җәмигъ мәчетендә ремонт эшләре киң колач белән узган. "Мәчетнең 39 тәрәзәсен алмаштырдык (бер тәрәзә 11 мең сум тора). Мәчет әйләнәсен койма белән әйләндереп алдык (аның гомуми озынлыгы 280 метр). Быел бик тә катлаулы ел булды", - дип белдерде С.Гайнетдинов. Шулай ук мәчет түбәсенә дә ремонт ясаганнар.

Балык бистәсендә һәм районның унҗиде авыл мәчетендә дини укулар башланып киткән. Җәмигъ мәчеттә дәресләрне "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлаган дүрт укытучы алып бара. Авылларда 11-12 укытучы гыйлем бирә. Балык бистәсе мәчетендә дәресләр атнаның дүрт көнендә үтә: чәршәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә, якшәмбе. Дәресләр ял көннәрендә өлкән буын вәкилләре өчен аерым оештырыла.

**Нияз САБИРҖАНОВ**

# Кайгыгызны уртаклашабыз

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз, Төркия Республикасында җир тетрәү аркасында булган фаҗигагә бәйле рәвештә, Төркия Президенты Абдуллаһ Гөлгә, илнең Премьер-министры Рәҗәп Тайип Эрдоганга мөрәҗәгать итте.

- ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән Төркиядәге җир тетрәү нәтиҗәсендә үз якыннарын югалтканнарның, бәла-казада зыян күргән төркиялеләрнең тирән кайгысын уртаклашам", - диелә Татарстан мөфтие Илдус Фәиз юллаган кайгынамәдә. - Зарар күрүчеләргә булдыра алганча ярдәм итүегезгә шигебез юк. Хәзерге вакытта вафат булучыларның гаиләләре ярдәмгә мохтаҗ, алар өчен югалту газабын кичерү авыр. Без дә, үз чиратыбызда, аларга Аллаһы Тәгаләнең сабырлык бирүен сорап һәм Ул биргән сынауларда халыкның сынмавын-сыгылмавын теләп дога кылабыз.

# ХАТЫНЫМ МИҢА ЕШ ҮПКӘЛИ

***Соңгы арада хатыным белән еш кына сүзгә киләбез. Сәбәпләре юк-бардан, әйтик, гомер туебызга чәчәк бәйләме алып кайтмаганга, кафега алып бармаганга, дусларга аның рөхсәтеннән башка нәрсә дә булса бирсәм һәм башка вак кына мәсьәләләрдән килеп чыга. Бер караганда, чүп кенә мәсьәләләр дә бит, ләкин каршылыкка кергәннән соң, мин үз-үземне битәрле башлыйм, гаепле итеп хис итәм. Хатыным намазлы һәм ул миңа, динебез кануннары буенча һәрбер гамәлне аның белән киңәшләшеп эшләргә тиешмен, дип әйтә. Мин аңа ир-атның солидар булырга тиешлеген әйтеп тә карыйм. Әмма ул берни дә аңламый, барыбер аның белән киңәшләшүемне сорый. Миңа нишләргә? Киңәш бирегезче.***

**ДИН ӘҺЕЛЕ ҖАВАБЫ:**

Хатыныңны шатландыру, аңа бүләкләр бирү, шаяру, матур сүзләр әйтү - пәйгамбәребезнең (с.г.в.) сөннәте. Ир-атка хатыны белән киңәшләшү хәерлерәк, әгәр дә ул берәр сорауда киңәшләшү-



не кирәк дип тапмаса, анысы да рөхсәт ителә. Бүләк бирмәгәнгә яки кафега алып бармаганга ирең белән сүзгә килү, араны бозу - шәригать буенча гөнаһ санала. Мөмкинлегегез булганда, чәчәк бәйләмнәре бирергә, шатландырырга, сабырлык күрсәтергә тырышыгыз, шул очракта Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешерсез. Аллаһ ярдәменнән ташламасын!

**ПСИХОЛОГ ФИКЕРЕ:**

Аңлавымча, биредә берничә проблема кисешә. Кемгә ярарга: хатынгамы, дусларгамы? Әлеге проблема белән бүгенге көндә һәр икенче гаилә очраша. Мондый очракта урталыкны табарга кирәк - ягъни бүре дә тук, сарык та исән булсын. Хатыныгызны әлеге канәгатьсезлеккә нинди сәбәпләр этәрә? Мөгаен, хатыныгыз сезнең тормышыгызда үзенең әһәмиятле урын тотуын аңларга телидер. Билгеле булганча, барлык яктан да килгән тормышта яшәгән, үз-үзеннән канәгать булган кеше юк-барга игътибар бирми. Хатыныгызда дусларыгызга, дөресрәге, аларның ихтияҗларына күбрәк игътибар итүегез көнләшү хисләре тудырган.

Тагын шуны да истән чыгармаска кирәк: хатын-кыз һәм ир-ат психологик яктан икесе ике төрле. Сезгә вак кына булып күренгән мәсьәләләр тормыш иптәшегез өчен бик тә әһәмиятле булырга мөмкин. Әгәр ул сезгә нык ышанса һәм үзенең фикере сезнең өчен әһәмиятле булуын сизсә, дусларыгыз белән аралашканга каршы килмәс иде. Моңа ирешү авыр түгел: иң мөһиме - аңа үзегезнең ихтирамыгызны күрсәтегез, аның фикерен тыңларга өйрәнегез. Кылган гамәлләрегезнең дөреслегенә тиешле дәлилләр дә китерү мөһим. Чикне узмау, урталыкны саклау үтә дә әһәмиятле. Киресе күзәтелгәндә, аның ихтирамын югалтачаксыз, абруегыз төшәчәк. Менә монысы - чыннан да, катлаулы мәсьәлә. Ислам диненә бәйле булган сорауларда ул үзе белән киңәшләшергә чакыра икән, димәк, хатыныгыз әлеге сорауларда үзен белемлерәк итеп хис итә. Шулай итеп, әлеге өлкәдә сезгә белемегезне тирәнәйтү кирәк. Чәчәк яки башка төрле бүләкләр бирүне билгеле бер көннәр белән генә бәйләү ярамый, һич көтмәгәндә, уйламаганда, гадәти көннәрдә дә үз мәхәббәтеңне раслау бик тә мөһим.

Кайбер мәсьәләләрдә ир-атка бәйле булган солидарлык хисе турында онытып торсагыз да була, бигрәк тә гаиләгезгә турыдан-туры зыян килгәндә (шулай ук динебез кануннары бозылганда). Әлеге проблеманың икенче ягы - бәхәс килеп чыкканда үзүзеңне ничек тотарга? Бу очракта үзеңнең үпкәңне озак саклау урынсыз, теләсә кайсы юл белән хатыныңның игътибарын башкага юнәлтү кирәк. Проблема шунда ки, кешедә үпкә никадәр күбрәк сакланса, аның башындагы уйлары да шулкадәр томанлырак була (аның тискәре хисләре артачак кына). Дөресен генә әйткәндә, хатын-кызлар бик эмоциональ булганга, аларны тискәре уйлардан арындыру авыр түгел, иң мөһиме - әлеге ситуациядә бирешмәү. Димәк, аның күңелен күтәрергә, иркәләргә, аның эчке дөньясын ачар өчен барысын да эшләргә кирәк.

***Җавап islam.ru сайтыннан алынды***

# Төзәтү

**Газетабызның 21 октябрь санында (№10) "Ноябрь аенда ничек ял итәчәкбез?" дип исемләнгән язма дөнья күргән иде. Дүртенче биттә урын алган әлеге мәкаләнең 5 нче абзацында (2 нче графа, астан 9 нчы юл) "6 нчы ноябрь" диясе урынга "7 нче ноябрь", дип ялгышлык киткән. Без укучыларыбыздан гафу үтенәбез һәм әлеге абзацны дөрес итеп түбәндәгечә укуларын үтенәбез: "Шулай итеп, быел Татарстанда 4 нче һәм 6 нчы ноябрь көннәре - эш көне булмаган бәйрәм көне, ә 7 нче ноябрь ял көне булып саналачак, дип хәбәр итә** *tatar-inform.ru сайты".*

# Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 29.10.2011 | 06:12 | 07:42 | 13:02 | 15:17 | 17:11 | 18:40 |
| Якшәмбе | 30.10.2011 | 06:14 | 07:44 | 13:02 | 15:15 | 17:09 | 18:38 |
| Дүшәмбе | 31.10.2011 | 06:16 | 07:46 | 13:02 | 15:13 | 17:07 | 18:36 |
| Сишәмбе | 1.11.2011 | 06:18 | 07:48 | 13:02 | 15:11 | 17:04 | 18:35 |
| Чәршәмбе | 2.11.2011 | 06:20 | 07:50 | 13:02 | 15:09 | 17:02 | 18:33 |
| Пәнҗешәмбе | 3.11.2011 | 06:21 | 07:52 | 13:02 | 15:07 | 17:00 | 18:31 |
| Җомга | 4.11.2011 | 06:23 | 07:54 | 13:02 | 15:06 | 16:58 | 18:29 |

*Мәгълүматлар muslem.ru сайтыннан алынды*

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №11 (108) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-511.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 27 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**